| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ<br>БУИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|---|

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29 июнь 2026 ел Буа шәһәре № 3-14

Буа муниципаль районы Советының 2017 елның 11 декабрендәге 6-27 номерлы «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына озак сроклы нигездә файдалануга бирү өчен өченче затлар хокукларыннан (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) азат булган муниципаль мөлкәт исемлегенә кертелгән Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль мөлкәтен (җир кишәрлекләреннән тыш) арендага бирү тәртибе турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законы (29.12.2025 ел редакциясе) нигезендә аренда шартларында муниципаль мөлкәттән нәтиҗәле файдалануны тәэмин итү, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1. Буа муниципаль районы Советының 2017 елның 11 декабрендәге 6-27 номерлы «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына озак сроклы нигездә файдалануга бирү өчен өченче затлар хокукларыннан (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) азат булган муниципаль мөлкәт исемлегенә кертелгән Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль мөлкәтен (җир кишәрлекләреннән тыш) арендага бирү тәртибе турында» карарына үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаның 5.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Тәртипнең 10 пунктында каралган шартларда кече һәм урта эшкуарлык субъекты белән төзелгән мөлкәтне арендалау шартнамәсе вакытыннан алда өзелгәндә, арендаторның мөлкәтне арендалау шартнамәсе буенча йөкләмәсен үтәмәвенә бәйле рәвештә яисә, әгәр арендатор Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның

23 декабрендәге  976 номерлы карары белән расланган әлеге тәртипнең 10 пунктында каралган критерийларга туры килми башласа, дәүләт мөлкәтеннән фактта файдалану турындагы хәбәр аны төзү хокукына сатулар нәтиҗәләре буенча мөлкәтне арендалау шартнамәсендә билгеләнгән аренда бәясеннән 100 процент күләмендә түләнергә тиеш.»

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында районның рәсми сайтында http://buinsk.tatarstan.ru. урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Совет рәисе Р.Р. Камартдинов